**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2016 ел, 4 май № 278

г. Казань

Татарстан Республикасында инвестицион климатны яхшырту һәм Россия Федерациясе субъектларындагы Инвестицион климат торышы илкүләм рейтингының иң яхшы тәҗрибәләрен кертү буенча проект офисын төзү турында

Петербург халыкара икътисадый форумы йомгаклары буенча Россия Федерациясе Президентының 2015 елның 14 июлендәге Пр-1366 нчы Йөкләмәләр исемлегенең 8 нче пунктын үтәү йөзеннән, шулай ук Татарстан Республикасында инвестицион климатны яхшырту максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасында инвестицион климатны яхшырту һәм Россия Федерациясе субъектларындагы Инвестицион климат торышы илкүләм рейтингының иң яхшы тәҗрибәләрен кертү буенча проект офисын төзергә.

2. Бу карарга теркәлгән Татарстан Республикасында инвестицион климатны яхшырту һәм Россия Федерациясе субъектларындагы Инвестицион климат торышы илкүләм рейтингының иң яхшы тәҗрибәләрен кертү буенча проект офисы турындагы нигезләмәне һәм аның составын расларга.

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2012 ел, 15 февраль, б-239 нчы, 2015 ел, 22 август, б-1850 нче, 2015 ел, 16 ноябрь, б-2580 нче боерыклары үз көчен югалткан дип санарга.

4. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2016\278.docx

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 ел, 4 май, 278 нче карары белән расланды

**Татарстан Республикасында инвестицион климатны яхшырту һәм Россия Федерациясе субъектларындагы Инвестицион климат торышы илкүләм рейтингының иң яхшы тәҗрибәләрен кертү буенча проект офисы турында нигезләмә**

1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Татарстан Республикасында инвестицион климатны яхшырту буенча проект офисы (алга таба – Проект офисы) эшчәнлеге эшмәкәрлек эшчәнлеге алып баруның уңай шартларын формалаштыруга, Татарстан Республикасында административ киртәләрне киметүгә, шулай ук Россия Федерациясе субъектларындагы Инвестицион климат торышы илкүләм рейтингының (алга таба – Илкүләм рейтинг) иң яхшы тәҗрибәләрен Татарстан Республикасында кертүгә юнәлдерелгән даими гамәлдә булган ведомствоара коллегиаль орган булып тора.

1.2. Проект офисы үзенең эшчәнлегендә Россия Федерациясе законнарына, Татарстан Республикасы законнарына, шулай ук әлеге Нигезләмәгә, еллык Илкүләм рейтингны үткәрү йомгаклары буенча билгеләнгән инвестицион климатны яхшыртуның төбәк тәҗрибәләренә, «Яңа проектларны үстерү буенча стратегик инициативалар агентлыгы» автоном коммерциячел булмаган оешмасының (алга таба – Агентлык) методик тәкъдимнәренә таянып эш итә.

1.3. Проект офисы составы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан раслана.

2. Проект офисының төп бурычлары һәм вазыйфалары

2.1. Проект офисының төп бурычлары булып түбәндәгеләр тора:

эшмәкәрлек һәм инвестицион эшчәнлек алып баруның уңай шартларын формалаштыру, Татарстан Республикасында административ киртәләрне киметү буенча өстенлекле юнәлешләрне билгеләү, шул исәптән Илкүләм рейтинг нәтиҗәләрен исәпкә алып;

алга таба Татарстан Республикасында кертү максаты белән Илкүләм рейтингның иң яхшы төбәк тәҗрибәләрен сайлап алу;

Илкүләм рейтинг күрсәткечләре нигезендә Татарстан Республикасында инвестицион климатны яхшырту буенча «юл картасы» чараларын үтәү;

Татарстан Республикасында инвестицион климат торышына тискәре йогынты ясый торган төп проблемаларны билгеләү һәм аларны бетерү буенча тәкъдимнәр кертү;

эшмәкәрлек эшчәнлеге алып баруның уңай шартларын формалаштыруга, Татарстан Республикасында административ киртәләрне киметүгә, шулай ук

Илкүләм рейтингның иң яхшы тәҗрибәләрен Татарстан Республикасында кертүгә юнәлдерелгән башка мәсьәләләрне карап тикшерү.

2.2. Проект офисы үзенә йөкләнгән бурычларны үтәү максатларында түбәндәге вазыйфаларны башкара:

Татарстан Республикасында уңай инвестицион климат формалаштыру;

Илкүләм рейтинг күрсәткечләре һәм «Яңа проектларны үстерү буенча стратегик инициативалар агентлыгы» АКБО Илкүләм эшмәкәрлек инициативасының «юл карталары» нигезендә Татарстан Республикасында инвестицион климатны яхшырту буенча «юл карталары» чараларын тормышка ашыру һәм аларны үтәү нәтиҗәләрен мониторинглау;

хәлне исәпкә алып оператив чаралар кабул итүне тәэмин иткән, эшмәкәрлек эшчәнлеге алып баруның уңай шартларын формалаштыруга һәм Татарстан Республикасында административ киртәләрне киметүгә юнәлдерелгән башка мәсьәләләрне карап тикшерү.

## 3. Проект офисының хокуклары

3.1. Проект офисы түбәндәге хокукларга ия:

Проект офисы эшендә катнашу өчен Татарстан Республикасы закон чыгару һәм башкарма хакимият органнары, федераль дәүләт хакимияте органнарының территориаль органнары, Татарстан Республикасы җирле үзидарә органнары, инвестицион эшчәнлек субъектлары, иҗтимагый һәм башка оешмалар вәкилләрен җәлеп итәргә;

Илкүләм рейтинг күрсәткечләре нигезендә Татарстан Республикасында инвестицион климатны яхшырту буенча «юл картасы» чараларын тормышка ашыру максатларында, Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнары, шулай ук федераль дәүләт хакимияте органнарының территориаль органнары, Татарстан Республикасы җирле үзидарә органнары, инвестицион эшчәнлек субъектлары, иҗтимагый һәм башка оешмалар өчен методик тәкъдимнәр эшләргә;

компетенциясе чикләрендә Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнарыннан, федераль дәүләт хакимияте органнарының территориаль органнарыннан, Татарстан Республикасы җирле үзидарә органнарыннан, инвестицион эшчәнлек субъектларыннан, иҗтимагый һәм башка оешмалардан Проект офисы тарафыннан карарлар кабул итү өчен кирәкле мәгълүмат соратып алырга;

Илкүләм рейтингның иң яхшы тәҗрибәләрен Татарстан Республикасында кертү мәсьәләләре буенча Татарстан Республикасы хокукый актлары проектларын эшләргә;

законнар нигезендә үз бурычларын һәм вазыйфаларын башкаруны тәэмин итүгә юнәлдерелгән башка хокукларны гамәлгә ашырырга.

4. Проект офисының эш тәртибе

4.1. Проект офисы утырышлары аның җитәкчесе (җитәкчесе урынбасары) карары буенча үткәрелә, ләкин ким дигәндә кварталга бер тапкыр. Проект офисы әгъзалары утырыш үткәрү турында тәкъдимнәр кертергә һәм көн тәртибен тәкъдим итәргә хокуклы.

4.2. Проект офисы җитәкчесе (җитәкчесе урынбасары) утырышларда рәислек итә, көн тәртибен раслый, эшне планлаштыра һәм Проект офисы карарларын тормышка ашыруны тикшерүдә тота.

4.3. Утырышларны үткәрү датасы һәм көн тәртибе Проект офисы җитәкчесе яки җитәкче урынбасары тарафыннан раслана.

4.4. Проект офисы эшендә кирәк булган очракта аның составына кермәгән дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары, иҗтимагый һәм башка оешмалар вәкилләре катнаша ала.

4.5. Карарлар утырышта катнашкан әгъзалар тавышларының күпчелеге белән кабул ителә. Тавышлар тигез булган очракта рәислек итүче тавышы хәлиткеч санала.

4.6. Проект офисы карарлары рекомендация характерында була, беркетмә белән рәсмиләштерелә һәм утырышны үткәргән көннән соң өч эш көне эчендә Проект офисы җитәкчесе яки аның урынбасары тарафыннан имзалана.

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 ел, 4 май, 278 нче карары белән расланды

**Татарстан Республикасында инвестицион климатны яхшырту һәм Россия Федерациясе субъектларындагы Инвестицион климат торышы илкүләм рейтингының иң яхшы тәҗрибәләрен кертү буенча проект офисы составы**

| | |
|---|---|
| Халиков Илдар Шәфкать улы | Татарстан Республикасы Премьер-министры, проект офисы җитәкчесе |
| Здунов Артём Алексеевич | Татарстан Республикасы икътисад министры, проект офисы җитәкчесе урынбасары |
| Хаҗиәхмәтов Булат Зөфәр улы | Татарстан Республикасы икътисад министры урынбасары, проект офисы секретаре |

Проект офисы әгъзалары:

| | |
|---|---|
| Афонин Андрей Геннадьевич | «Татарстан Республикасының Эшмәкәрлеккә булышлык күрсәтү фонды» коммерциячел булмаган оешмасы генераль директоры (килешү буенча) |
| Багров Юрий Николаевич | Татарстан Республикасы мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрының беренче урынбасары |
| Габидуллин Руслан Илсөяр улы | «Татарстан Республикасы Инвестиция-венчур фонды» коммерциячел булмаган оешмасы директоры урынбасары (килешү буенча) |
| Газизов Азат Хәлил улы | «Опора России» кече һәм урта эшмәкәрлек гомумроссия иҗтимагый оешмасының Татарстан төбәк бүлеге рәисе, «Казан сәүдә-сәнәгать предприятиесе» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте генераль директоры (килешү буенча) |
| Гайнетдинов Ренат Вагыйз улы | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Икътисад, финанс һәм дәүләт мөлкәте белән эш итү идарәсе башлыгы |
| Галиев Инсаф | Татарстан Республикасының Инвестицион үсеш |

| | |
|---|---|
| Мөшәррәф улы | агентлыгы җитәкчесенең беренче урынбасары |
| Госсамова Чулпан Фәрит кызы | Федераль салым хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе җитәкчесе урынбасары (килешү буенча) |
| Демидов Сергей Анатольевич | Татарстан Республикасы җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрының беренче урынбасары |
| Жуйков Владимир Васильевич | Татарстан Республикасы Сәүдә-сәнәгать палатасы идарәсе рәисе урынбасары (килешү буенча) |
| Заһидуллин Рөстәм Илдус улы | Татарстан Республикасы юстиция министрының беренче урынбасары |
| Кудряшев Владимир Николаевич | Татарстан Республикасы төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министры урынбасары |
| Кузнецов Иван Владимирович | Казан шәһәре муниципаль берәмлеге башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары (килешү буенча) |
| Поминов Андрей Иванович | Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министрының беренче урынбасары |
| Сафиуллин Дамир Һарун улы | Татарстан Республикасы сәнәгать һәм сәүдә министры урынбасары |
| Сёмушкин Алексей Васильевич | Транспорт өлкәсендә күзәтчелек федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча автомобиль юлында дәүләт күзәтчелеге идарәсе башлыгы урынбасары – Татарстан Республикасы буенча автомобиль юлында дәүләт күзәтчелеге баш дәүләт инспекторы урынбасары (килешү буенча) |
| Таҗетдинова Клара Алексеевна | Татарстан Республикасы хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министры урынбасары |
| Титов Николай Леонидович | Татарстан Республикасы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрының беренче урынбасары |

| | |
|---|---|
| Фәйзрәхманов Марат Җәүдәт улы | Татарстан Республикасы финанс министрының беренче урынбасары – Татарстан Республикасы Казначылык департаменты директоры |
| Хәйретдинов Альберт Марат улы | Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе җитәкчесе урынбасары (килешү буенча) |
| Хисаметдинов Ильяс Илдар улы | «Сетевая компания» ачык акционерлык җәмгыяте генераль директоры урынбасары – хезмәтләрне тормышка ашыру буенча директор (килешү буенча) |
| Чукин Артем Викторович | Татарстан Республикасы транспорт һәм юл хуҗалыгы министры урынбасары |
| Шәйхетдинов Хәлил Хәмит улы | Татарстан Республикасы яшьләр эшләре һәм спорт министрының беренче урынбасары |
| Шакиров Минсәгыйть Закир улы | Татарстан Республикасының муниципаль берәмлекләре советы (килешү буенча) |
| Йосыпов Камил Раиф улы | «Деловая Россия» гомумроссия иҗтимагый оешмасының Татарстан төбәк бүлеге рәисе (килешү буенча). |

---

F:\KARAR\2016\278_2.docx